


Әлеге олкәнен Кызыл Октябрь районы vзәге булган Уразавыл авылында татар язучысы Кави Нәжмигә һәйкәл-бюст ачылган. Белгәнебезчә, хәзерге татар прозасы һәм поэзиясенә нигез салучыларнын берсе, ТАССР Язучылар берлеге идарәсенен беренче рәисе Кави Нәжми 1901 елнын 15 декабрендә Түбән Новгород губернасынын Красный Остров авылында туган.

Тантанада Кави Нәжминен оныгы, Казан дәvләт аграр уни-верситетынын фәлсәфә һәм хокук кафедрасын житәкчесе Фәридә Нәжметдинова, шулай ук язучынын оныкчыклары Константин белән Кирилл Колпаковлар да катнашканнар. – Кави Нәжми татар халкы һәм Түбән Новгород татарлары очен генә тvгел, ботен Түбән Новгород олкәсе очен дә әһәмиятле шәхес. Анын тормыш юлы уртак тарихыбызны чагылдыра. Анын әсәрләре фронттагы сугышчыларны корәшкә һәм жинvгә рухландырган, ә сугыштан сон илне торгызу һәм vстерv эшенә ондәгән», - ди һәйкәл-бюст ачу тантанасында Түбән Новгород олкәсе губернаторы Глеб Никитин.

Глеб Никитин Татарстан очен моһим булган Рәшит Ваһапов, Хәйдәр Бигичев һәм Кави Нәжми кебек шәхесләрнен Түбән Новгород жирлегеннән чыгуы Түбән Новгород олкәсе белән Татарстанны мәдәни яктан берләштерvен әйткән. Шулай ук быел Кави Нәжминен тууына 125 ел тула. Губернатор язучынын юбилеен декабрьдә тантаналы рәвештә билгеләп vтәргә жыенуларын хәбәр иткән.

– Ботендонья татар конгрессы да кvренекле шәхесләребезнен юбилейларына зур игътибар бирә. Габдулла Тукайнын тууына – 140, Муса Жәлил белән Сара Садыйкованын тууына – 120, Кави Нәжминен тууына 125 ел тулу унаеннан торле тобәкләрдә истәлекле чаралар vткәрелә, мемориаль такталар, бюстлар һәм һәйкәлләр ачыла, китаплар басыла.

Жәмәгатьчелекнен башлангычларына житәкчелек тә ярдәм иткәндә, бу халык һәм ил очен зур бvләккә әверелә.Ростәм Миннехановнын йокләмәсе, шулай ук Глеб Никитиннын башлангычны хуп-лавы һәм ярдәм итvе нәтижәсендә бу идеянен бvген тормышка ашуы безнен очен аеруча куанычлы», – диде чыгышында Татарстан Республикасы Премьер-министры урынбасары, Ботендонья татар конгрессынын Милли Шура рәисе Васил Шәйхразыев.

Проектны гамәлгә ашыруда Рәшит Ваһапов исемендәге фонд директоры, Түбән Новгород татарларынын Казандагы «Якташлар» жәмгыяте рәисе Рифат Фәттахов зур роль уйнаган. Ул: «Бvгенге вакыйганын тарихи әһәмияте зур. Бу – гаделлекне торгызуга юнәлтелгән әхлакый һәм фәлсәфи гамәл. Кави Нәжминен исеме тарихта һәм халык хәтерендә лаеклы урынын янадан алды…», - дип танданада әйткән.

**Н.ХӘЛИЛ әзерләде,**

**Фото: «Интертат.ру» дан**